ГЛАВА НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление Карар

19 октябрь 2020 ел № 2

Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Урта Шүләнгер авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган граждannар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Түбән Шүләнгер авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-46 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Урта Шүләнгер авылы почта хезмәткәре Хамидуллина Раушания Миннахметовна Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлегенең Урта Шүләнгер торак пунктында 2020 елның 10 ноябрь гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләнгер авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләнгер
авыл җирлеге башлыгы: Е.М.Михайлова